**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## Об утверждении описаний орденов, медали ордена, медалей и нагрудного знака к почетным званиям Республики Татарстан

В соответствии со статьей 3 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Утвердить:
описание ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» (приложение № 1);
описание ордена «Дуслык» (приложение № 2);
описание медали ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» (приложение № 3);
описание медали «За доблестный труд» (приложение № 4);
описание медали «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан» (приложение № 5);
описание медали «Родительская доблесть» (приложение № 6);
описание медали «Ана даны – Материнская слава» (приложение № 7);
описание медали «100 лет образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики» (приложение № 8);
описание медали «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны нефти Татарстана» (приложение № 9);
описание нагрудного знака к почетным званиям Республики Татарстан (приложение № 10).

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:
обеспечить в установленном порядке финансирование изготовления орденов, медалей ордена, медалей и нагрудных знаков к почетным званиям Республики Татарстан;
принять иные решения, необходимые для реализации настоящего Указа.

3. Управлению делами Президента Республики Татарстан обеспечить изготовление орденов, медалей ордена, медалей и нагрудных знаков к почетным званиям Республики Татарстан.

4. Признать утратившими силу акты Президента Республики Татарстан по перечню согласно приложению № 11.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
16 мая 2022 года
№ УП-336

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 16 » мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан»**

Знак ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» изготовлен из серебра 925-й пробы с применением методов золочения и эмалирования. Имеет в основе восьмилучевую серебряную звезду, лучи делятся на золоченые и серебряные с полированными гранями. Расстояние между противолежащими концами звезды – 50 мм. В центре звезды – круглый позолоченный медальон диаметром 20 мм с изображением барса. По окружности медальона на зеленом эмалевом поле между двумя выпуклыми ободками – обрамление из татарского народного орнамента, в основании располагается надпись «ТАТАРСТАН». На оборотной стороне знака в центре – номер ордена.


Знак ордена при помощи декоративного ушка в виде тюльпана и кольца соединяется с пятиугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан). Ширина ленты – 24 мм, ширина зеленой и красной полос – 11 мм, ширина белой полосы – 2 мм.

Цветное графическое изображение ордена прилагается.


К ордену прилагается орденская планка, представляющая собой прямоугольную колодку размерами 10 на 24 мм, обтянутую шелковой муаровой лентой зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан). В центре ленты помещен позолоченный тюльпан. Ширина красной и зеленой полос – 11 мм, белой полосы – 2 мм.

Приложение
к описанию ордена
«За заслуги перед
Республикой Татарстан»

**Цветное графическое изображение**
**ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан»**



Лицевая сторона



Оборотная сторона

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 16 » мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**ордена «Дуслык»**

Знак ордена «Дуслык» изготовлен из серебра 925-й пробы с применением методов золочения и эмалирования. Представляет собой восьмилучевую позолоченную звезду, лучи которой образуют пятиугольники. Поверх горизонтальных и вертикальных лучей – цветочный орнамент. Диагональные лучи в виде штралов. Расстояние между противолежащими концами звезды – 52 мм.

В центре звезды – круглый медальон диаметром 28 мм с выпуклой позолоченной каймой. По окружности медальона на серебряном поле – изображение цветков тюльпана. В центре медальона, покрытом синей эмалью, – серебряное стилизованное изображение Казанского Кремля.

На оборотной стороне знака поверх лучей – цветочный орнамент. В центре оборотной стороны знака – круглый медальон диаметром 28 мм. В центре медальона – номер ордена, в верхней части по окружности – надпись на татарском языке «ДУСЛЫК», в нижней части по окружности – надпись на русском языке «ДРУЖБА».

Все изображения и надписи рельефные.


Знак ордена при помощи ушка и кольца соединяется с прямоугольной колодкой размерами 28 на 50 мм, нижняя часть которой в виде пятиугольника с отверстием для продевания ленты и ушком. Колодка обтянута синей шелковой муаровой лентой, в центре которой – три полосы: зеленая, белая и красная (цвета Государственного флага Республики Татарстан). Ширина ленты – 28 мм, ширина зеленой и красной полос – 4 мм, ширина белой полосы – 1 мм.

Цветное графическое изображение ордена прилагается.


К ордену прилагается орденская планка, представляющая собой прямоугольную колодку размерами 10 на 24 мм, обтянутую синей шелковой муаровой лентой, в центре которой – три полосы: зеленая, белая и красная (цвета Государственного флага Республики Татарстан). Ширина ленты – 24 мм, ширина зеленой и красной полос – 4 мм, ширина белой полосы – 1 мм.

Приложение
к описанию ордена «Дуслык»

**Цветное графическое изображение
ордена «Дуслык»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

___________

Приложение № 3
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «16» мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан»**

Медаль ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан» изготовлена из серебра 925-й пробы с применением метода золочения. Имеет форму круга диаметром 32 мм, окаймленного с обеих сторон ободком.

На лицевой стороне медали изображен знак ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан».

На оборотной стороне медали в центре – номер медали, в верхней части по окружности – надпись в две строки на татарском языке «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН», в нижней части по окружности – надпись в две строки на русском языке «ЗА ЗАСЛУГИ ПЕРЕД РЕСПУБЛИКОЙ ТАТАРСТАН».

Все изображения и надписи рельефные.


Медаль при помощи декоративного ушка в виде серебряного тюльпана и кольца соединяется с пятиугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан). Ширина ленты – 24 мм, ширина зеленой и красной полос – 11 мм, ширина белой полосы – 2 мм.

Цветное графическое изображение медали прилагается.

К медали прилагается планка, представляющая собой прямоугольную колодку размерами 10 на 24 мм, обтянутую шелковой муаровой лентой зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан). В центре ленты помещен серебряный тюльпан. Ширина красной и зеленой полос – 11 мм, белой полосы – 2 мм.

Приложение
к описанию медали ордена
«За заслуги перед
Республикой Татарстан»

**Цветное графическое изображение**
**медали ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

---

Приложение № 4
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «16» мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали «За доблестный труд»**

Медаль «За доблестный труд» изготовлена из серебра 925-й пробы. Имеет форму круга диаметром 32 мм.


На лицевой стороне медали в центре изображен круг, окаймленный ободком. В центре круга – изображения нефтяной вышки, двух строительных кранов, архитектурной капители, автомобиля КамАЗ, раскрытой книги. В нижней части лицевой стороны медали – изображение венка из перекрещивающихся колосьев, в верхней – надпись по окружности «ХЕЗМӘТКӘ ДАН – СЛАВА ТРУДУ», над надписью по окружности – изображение шестеренки. На оборотной стороне медали – изображение лавровой ветви, под ней – номер медали. Все изображения и надписи рельефные (выпуклые).

Медаль при помощи ушка и кольца соединяется с пятиугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой серо-зелено-бело-красно-серого цвета. Ширина ленты – 24 мм, ширина каждой из серых полос – 8 мм, ширина зеленой и красной полос – 3 мм, ширина белой полосы – 2 мм.


Цветное графическое изображение медали прилагается.

Приложение
к описанию медали
«За доблестный труд»

**Цветное графическое изображение
медали «За доблестный труд»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

___________

Приложение № 5
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «16» мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан»**

Медаль «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан» изготовлена из серебра 925-й пробы и имеет форму круга диаметром 32 мм, с выпуклым бортиком с обеих сторон.

На лицевой стороне медали располагается карта Республики Татарстан золотистого цвета со схематическим изображением границ муниципальных районов и городских округов.

По окружности медали проходят две лавровые ветви, перекрещенные внизу.

В верхней части медали – изображение Государственного герба Республики Татарстан.

На оборотной стороне медали в центре – номер медали, в верхней части по окружности в три строки расположена надпись на татарском языке «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ҮСТЕРҮДӘГЕ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН», в нижней части по окружности в три строки – надпись на русском языке «ЗА ЗАСЛУГИ В РАЗВИТИИ МЕСТНОГО САМОУПРАВЛЕНИЯ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН».


Все изображения рельефные.

Медаль при помощи ушка и кольца соединяется с пятиугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой. Ширина ленты – 24 мм. Лента четырехцветная: по обоим краям ленты – полосы золотистого цвета шириной 2 мм, в центре – полоса белого цвета шириной 2 мм, слева от нее – полоса зеленого цвета, справа – полоса красного цвета, каждая шириной 9 мм.


Цветное графическое изображение медали прилагается.

Приложение
к описанию медали
«За заслуги в развитии
местного самоуправления
в Республике Татарстан»

**Цветное графическое изображение
медали «За заслуги в развитии местного самоуправления
в Республике Татарстан»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

___________

Приложение № 6
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «16» мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали «Родительская доблесть»**

Медаль «Родительская доблесть» изготовлена из серебра 925-й пробы с применением метода золочения и представляет собой серебряный цветок тюльпана с тремя лепестками, смотрящими влево, вверх и вправо. Цветок снизу и по краям окаймлен золоченой лентой, концы которой заходят за лепестки. На ленту нанесены надписи слева направо на русском языке «РОДИТЕЛЬСКАЯ ДОБЛЕСТЬ», на татарском языке «АТА-АНА ФИДАКАРЬЛЕГЕ». Поверх цветка золоченое изображение подвесной деревянной колыбели с занавесью и завернутым в пеленку ребенком в колыбели. Ширина медали – 32 мм, высота от основания до верха центрального лепестка – 42 мм, ширина золоченой ленты – 4 мм.

На оборотной стороне медали: в центре – номер медали; по окружности – татарский народный орнамент, который прерывается вверху изображением цветка тюльпана, внизу – надписью «ТАТАРСТАН».

Все изображения и надписи рельефные.

На мужском костюме носится медаль, соединенная при помощи кольца и ушка с прямоугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан). Ширина ленты – 24 мм, ширина зеленой и красной полос – 11 мм, ширина белой полосы – 2 мм. Размеры колодки – 28 на 35 мм.

В верхней части колодки – золотистая фигурная рамка.

В нижней части наложены две расходящиеся в стороны золотистые лавровые ветви с ушком. Вдоль основания колодки идут прорези, сквозь которые продета шелковая муаровая лента. Основание колодки имеет булавку для крепления медали к одежде.


На женском костюме носится медаль, соединенная при помощи кольца и ушка с колодкой в виде банта из шелковой муаровой ленты зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан).

В центре колодки – вертикальная золотая лавровая ветвь с ушком. Ветвь при помощи штифта фиксирует бант к основанию колодки размером 15 на 25 мм. Ширина ленты – 24 мм, ширина зеленой и красной полос – 11 мм, ширина белой полосы – 2 мм. Основание колодки имеет булавку для крепления медали к одежде.

Цветные графические изображения медали прилагаются.

Приложение
к описанию медали
«Родительская доблесть»

**Цветное графическое изображение
медали «Родительская доблесть», предназначенной для ношения
на мужском костюме**





Лицевая сторона




Оборотная сторона

**Цветное графическое изображение
медали «Родительская доблесть», предназначенной для ношения
на женском костюме**




Лицевая сторона




Оборотная сторона

---

Приложение № 7
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 16 » мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали «Ана даны – Материнская слава»**

Медаль «Ана даны – Материнская слава» изготавливается из металла серебристого цвета, имеет форму листообразной пальметты размером 50 на 43 мм.

На лицевой стороне медали в центре размещается коралл, закрепленный в наст. В нижней части расположен выпуклый цветок в виде тюльпана, в левую и правую стороны от которого, вокруг камня, развивается выпуклый цветочно-растительный орнамент.

По кругу располагаются надписи: в левой части – на татарском языке «АНА ДАНЫ», в правой части – на русском языке «МАТЕРИНСКАЯ СЛАВА».

На оборотной стороне медали в центре размещается выпуклый герб Республики Татарстан, над которым – надпись «МЕДАЛЬ». Ниже герба на 3 мм – листообразный растительный орнамент и порядковый номер медали.


Медаль при помощи ушка и кольца соединяется с металлической пластинкой в виде стилизованного Государственного флага Республики Татарстан, выполненной в технике перегородчатой эмали с использованием зеленого, белого и красного цветов.

На оборотной стороне пластинки – булавка для крепления медали к одежде.


Цветное графическое изображение медали прилагается.

Приложение
к описанию медали
«Ана даны – Материнская слава»

**Цветное графическое изображение
медали «Ана даны – Материнская слава»**




Лицевая сторона




Оборотная сторона

___

Приложение № 8
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «16» мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали «100 лет образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики»**

Медаль «100 лет образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики» изготовлена из серебра 925-й пробы и имеет форму круга диаметром 32 мм, с выпуклым бортиком с обеих сторон. Поверхность медали матовая шлифованная.

На лицевой стороне медали изображен силуэт карты Республики Татарстан, от которого исходят лучи. На силуэт по центру нанесена надпись «ТАТАРСТАН».

По окружности медали изображен татарский народный орнамент, который прерывается вверху изображением цветка тюльпана, внизу – надписью «1920–2020».

Силуэт карты с лучами отделен от орнамента выпуклым кантом по окружности диаметром 25 мм.

На оборотной стороне медали: в центре – номер медали; по окружности – татарский народный орнамент; по окружности меньшего диаметра в верхней части – надпись на татарском языке «ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ 100 ЕЛ», в нижней части – надпись на русском языке «100 ЛЕТ ОБРАЗОВАНИЯ ТАССР».


Надпись «ТАТАРСТАН» выполнена на уровне основного серебряного фона медали. Все остальные изображения и надписи рельефные. Все рельефные (выпуклые) элементы покрыты золотом 999-й пробы.

Медаль при помощи ушка и кольца соединяется с пятиугольной металлической колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой. Ширина ленты – 24 мм. Лента многоцветная, слева направо на ней расположены полосы: синяя – шириной 1,5 мм, красная – шириной 10,5 мм, зеленая – шириной 5,6 мм, белая – шириной 0,8 мм, красная – шириной 5,6 мм.

Цветное графическое изображение медали прилагается.

Приложение
к описанию медали
«100 лет образования Татарской
Автономной Советской
Социалистической Республики»

**Цветное графическое изображение**
**медали «100 лет образования Татарской Автономной Советской**
**Социалистической Республики»**




Лицевая сторона




Оборотная сторона

___________

Приложение № 9
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 16 » мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**медали «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны нефти Татарстана»**

Медаль «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны нефти Татарстана» изготовлена из серебра 925-й пробы и имеет форму круга диаметром 32 мм, окаймленного с двух сторон ободком золотистого цвета. Поверхность медали матовая шлифованная.

На лицевой стороне медали по длине окружности нанесен татарский народный орнамент. В центре изображена географическая карта Татарстана. На карте юго-восток республики, в отличие от общей полированной части, выделен рельефной поверхностью и, как и вся карта в целом, обрамлен тонким кантом.

В центре выделенной рельефной части изображен мемориал в виде фонтана, символизирующего добычу трех миллиардов тонн нефти.

Над картой республики расположена цифра «3», под картой – надпись «ТАТАРСТАН».

Вдоль внутренней окружности татарского народного орнамента в одну строку расположены надписи: в левой части – на татарском языке «МИЛЛИАРД ТОННА НЕФТЬ», в правой части – на русском языке «МИЛЛИАРДА ТОНН НЕФТИ».

На оборотной стороне медали в центре по углубленной поверхности – изображение лавровой ветви, под ним – номер медали.

По окружности медали расположены надписи, отделенные от изображения ветви с номером выступающим кантом: в верхней части полированного круга – «1943 – 2007» с двумя четырехконечными звездами по сторонам; далее по окружности слева направо шрифтом чуть меньшего размера – «1943–1971 – I млрд.», «1971–1981 – II млрд.» и «1981–2007 – III млрд.».


Все изображения и надписи рельефные, золотистого цвета.

Медаль при помощи ушка и кольца соединяется с пятиугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой. Ширина ленты – 24 мм. Лента трехцветная: слева – полоса зеленого цвета, справа – полоса красного цвета, каждая – шириной 10 мм, по краям ленты – полосы золотистого цвета шириной 2 мм.

Цветное графическое изображение медали прилагается.

Приложение
к описанию медали
«В ознаменование добычи
трехмиллиардной тонны
нефти Татарстана»

**Цветное графическое изображение
медали «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны
нефти Татарстана»**




Лицевая сторона




Оборотная сторона

___

Приложение № 10
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «16» мая 2022 года

№ УП-336

**Описание**
**нагрудного знака к почетным званиям Республики Татарстан**

Нагрудный знак к почетным званиям Республики Татарстан изготовлен из серебра 925-й пробы. Имеет форму круга диаметром 32 мм.

На лицевой стороне знака – изображение динамичной композиции из наклонных разновеликих полос и позолоченной пятиконечной звезды на переднем плане, символизирующей стремление к новым трудовым достижениям. По позолоченной окружности знака между прерывающимися ободками надписи:

слева – «ХАЛЫК АРТИСТЫ», «ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ», «ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ», «ХАЛЫК УКЫТУЧЫСЫ», «ХАЛЫК РӘССАМЫ» и справа соответственно – «НАРОДНЫЙ АРТИСТ», «НАРОДНЫЙ ПИСАТЕЛЬ», «НАРОДНЫЙ ПОЭТ», «НАРОДНЫЙ УЧИТЕЛЬ», «НАРОДНЫЙ ХУДОЖНИК» (для знаков к почетным званиям, предусмотренным пунктами 1–5 статьи 13 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан»);

слева – «АТКАЗАНГАН ХЕЗМӘТКӘР» и справа – «ЗАСЛУЖЕННЫЙ РАБОТНИК» (для знаков к почетным званиям, предусмотренным пунктами 6–47 статьи 13 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан»).

На оборотной стороне знака – надпись «ТАТАРСТАН», под ней – изображение лавровой ветви.


Все изображения и надписи рельефные (выпуклые).

Нагрудный знак при помощи ушка и кольца соединяется с прямоугольной колодкой, обтянутой шелковой муаровой лентой зелено-бело-красного цвета (цвета Государственного флага Республики Татарстан). Ширина ленты – 13 мм, ширина зеленой и красной полос – 6 мм, ширина белой полосы – 1 мм.

Цветные графические изображения нагрудного знака прилагаются.

Приложение
к описанию нагрудного
знака к почетным званиям
Республики Татарстан

**Цветное графическое изображение
нагрудного знака к почетному званию Республики Татарстан
«Народный артист Республики Татарстан»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

**Цветное графическое изображение
нагрудного знака к почетному званию Республики Татарстан
«Народный писатель Республики Татарстан»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

**Цветное графическое изображение**
**нагрудного знака к почетному званию Республики Татарстан**
**«Народный поэт Республики Татарстан»**




Лицевая сторона




Оборотная сторона

**Цветное графическое изображение
нагрудного знака к почетному званию Республики Татарстан
«Народный учитель Республики Татарстан»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

**Цветное графическое изображение нагрудного знака к почетному званию Республики Татарстан «Народный художник Республики Татарстан»**




Лицевая сторона




Оборотная сторона

**Цветное графическое изображение
нагрудного знака к почетным званиям Республики Татарстан,
предусмотренным пунктами 6–47 статьи 13 Закона Республики
Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных
наградах Республики Татарстан»**



Лицевая сторона




Оборотная сторона

---

Приложение № 11
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 16 » мая 2022 года

№ УП-336

**Перечень**
**актов Президента Республики Татарстан, утративших силу**

1. Указ Президента Республики Татарстан от 16 июня 2004 года № УП-460 «О мерах по реализации Закона Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан».

2. Указ Президента Республики Татарстан от 25 ноября 2004 года № УП-728 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О мерах по реализации Закона Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан».

3. Указ Президента Республики Татарстан от 4 мая 2007 года № УП-221 «Об утверждении описания медали «В ознаменование добычи трехмиллиардной тонны нефти Татарстана».

4. Пункт 2 Указа Президента Республики Татарстан от 22 июня 2010 года № УП-396 «Об утверждении форм (образцов) удостоверений к государственным наградам Республики Татарстан и форм наградного листа».

5. Указ Президента Республики Татарстан от 22 июня 2010 года № УП-397 «Об утверждении описания государственной награды Республики Татарстан – медали «Ана даны – Материнская слава», формы (образца) удостоверения к ней и формы наградного листа».

6. Указ Президента Республики Татарстан от 22 августа 2011 года № УП-510 «Об утверждении описания медали «За заслуги в развитии местного самоуправления в Республике Татарстан».

7. Указ Президента Республики Татарстан от 27 декабря 2011 года № УП-876 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам награждения медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава».

8. Указ Президента Республики Татарстан от 28 августа 2015 года № УП-809 «Об утверждении описаний ордена «Дуслык» и медали ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан».

9. Указ Президента Республики Татарстан от 2 сентября 2015 года № УП-824 «О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «Об утверждении описаний ордена «Дуслык» и медали ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан».

10. Пункт 2 приложения к Указу Президента Республики Татарстан от 12 августа 2016 года № УП-684 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам награждения государственными наградами Республики Татарстан и поощрения Благодарностью Президента Республики Татарстан».

11. Указ Президента Республики Татарстан от 12 октября 2019 года № УП-620 «Об утверждении описания медали «100 лет образования Татарской Автономной Советской Социалистической Республики».

12. Распоряжение Президента Республики Татарстан от 16 июня 2004 года № 113 «Об организации изготовления орденов, медалей и нагрудных знаков Республики Татарстан».

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы орденнарының, орден медаленең, медальләренең һәм мактаулы исемнәренә күкрәк тамгаларының тасвирламаларын раслау турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:
«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены тасвирламасын (1 нче кушымта);
«Дуслык» ордены тасвирламасын (2 нче кушымта);
«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале тасвирламасын (3 нче кушымта);
«Фидакарь хезмәт өчен» медале тасвирламасын (4 нче кушымта);
«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале тасвирламасын (5 нче кушымта);
«Ата-ана фидакарьлеге» медале тасвирламасын (6 нчы кушымта);
«Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын (7 нче кушымта);
«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тасвирламасын (8 нче кушымта);
«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале тасвирламасын (9 нчы кушымта);
Татарстан Республикасының мактаулы исеменә күкрәк тамгасының тасвирламасын (10 нчы кушымта).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
Татарстан Республикасы орденнарын, орден медальләрен, медальләрен һәм мактаулы исемнәренә күкрәк тамгаларын әзерләүне билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;
әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсенә Татарстан Республикасы орденнарын, орден медальләрен, медальләрен һәм мактаулы исемнәренә күкрәк тамгаларын әзерләүне әзерләүне тәэмин итәргә.

4. 11 нче кушымта нигезендәге исемлек буенча Татарстан Республикасы Президенты актларын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 16 май
№ ПУ-336

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 16 » маендагы
ПУ-336 номерлы Указына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен»**
**ордены тасвирламасы**

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены билгесе алтын йөгертү һәм эмальләү ысулларын кулланып, 925 нче пробалы көмештән ясала. Нигезендә сигез нурлы көмеш йолдыз сурәте, кырлары шомартылган нурлар алтын йөгертелгән һәм көмеш нурларга бүленә. Йолдызның кара-каршы очлары арасы – 50 мм. Йолдызның уртасында – барс сурәте төшерелгән 20 мм диаметрлы алтын йөгертелгән түгәрәк медальон. Медальонның әйләнәсе буенча яшел эмаль җирлектә кабарынкы ике кайма арасында татар милли бизәкләреннән кыса, аста «ТАТАРСТАН» дигән язу урнаштырылган. Билгенең икенче ягында уртада – орденның номеры.


Орден билгесе лалә чәчәге рәвешендәге декоратив элмәк һәм бөҗра ярдәмендә яшел, ак, кызыл төсләрдәге (Татарстан Республикасының Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган бишпочмаклы колодкага беркетелгән. Тасманың киңлеге – 24 мм, яшел һәм кызыл юллар киңлеге – 11 мм, ак юлныкы – 2 мм.

Орденның төсле график сурәте кушымтада бирелә.


Орден белән бергә 10 га 24 мм зурлыктагы турыпочмаклы колодка рәвешендәге, яшел, ак, кызыл төсләрдәге (Татарстан Республикасының Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган орден планкасы бирелә. Тасманың уртасында алтын йөгертелгән лалә чәчәге урнаштырылган. Яшел һәм кызыл юллар киңлеге – 11 мм, ак юл киңлеге – 2 мм.

«Татарстан Республикасы
алдындагы казанышлар өчен»
ордены тасвирламасына
кушымта

**«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен»
орденының төсле график сурәте**



Алгы ягы



Икенче ягы

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 16 » маендагы
ПУ-336 номерлы Указына
2 нче кушымта

**«Дуслык» ордены**
**тасвирламасы**

«Дуслык» ордены билгесе алтын йөгертү һәм эмальләү ысулларын кулланып, 925 нче пробалы көмештән ясала. Нурлары бишпочмаклар ясаучы сигез нурлы алтын йөгертелгән йолдыз рәвешендә ясалган. Горизонталь һәм вертикаль нурлары өстендә – чәчәк орнаменты. Диагональ нурлары штрал рәвешендә. Йолдызның кара-каршы очлары арасы 52 мм тәшкил итә.

Йолдызның уртасында – алтын йөгертелгән кабарынкы каймалы 28 мм диаметрдагы түгәрәк медальон. Медальон әйләнәсендәге көмеш яссы өслектә – лалә чәчәкләре сурәте. Медальонның зәңгәр эмаль йөгертелгән урта өлешендә – Казан Кремленең стильләштерелгән көмеш сурәте.

Билгенең икенче ягында нурлар өстендә – чәчәк орнаменты. Билгенең икенче ягында уртада – 28 мм диаметрдагы түгәрәк медальон. Медальонның уртасында – орденның номеры, әйләнәнең өске өлешендә – татар телендә «ДУСЛЫК» дигән, әйләнәнең аскы өлешендә – рус телендә «ДРУЖБА» дигән язулар.

Барлык сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән.

Орден билгесе элмәк һәм бөжра ярдәмендә 28 гә 50 мм зурлыктагы турыпочмаклы колодкага беркетелә, аның аскы өлеше тасма киертү өчен тишемле һәм элмәкле бишпочмак рәвешендә була. Колодка урта өлешенә яшел, ак һәм кызыл төстәге өч юл (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) төшерелгән ялтыравыклы зәңгәр ефәк тасма белән тышланган. Тасманың киңлеге – 28 мм, яшел һәм кызыл юллар киңлеге – 4 мм, ак юл киңлеге – 1 мм.


Орденның төсле график сурәте кушымтада бирелә.

Орден белән бергә 10 га 24 мм зурлыктагы турыпочмаклы колодка рәвешендәге, урта өлешенә яшел, ак һәм кызыл төстәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) өч юл төшерелгән ялтыравыклы зәңгәр ефәк тасма белән тышланган орден планкасы бирелә. Тасманың киңлеге – 24 мм, яшел һәм кызыл юллар киңлеге – 4 мм, ак юл киңлеге – 1 мм.


___

«Дуслык» ордены тасвирламасына кушымта

# «Дуслык» орденының төсле график сурәте



Алгы ягы




Икенче ягы

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «_16_» _маендагы___
ПУ-336_ номерлы Указына
3 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале тасвирламасы**

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале алтын йөгертү ысулын кулланып, 925 нче пробалы көмештән ясала. Ике ягыннан да кайма белән уратып алынган 32 мм диаметрдагы түгәрәк рәвешендә.

Медальнең алгы ягында «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены билгесе сурәтләнгән.

Медальнең икенче ягында уртада – медаль номеры, өске ягында әйләнә буйлап – татар телендә ике юлда «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН» дигән, аскы ягында әйләнә буйлап – рус телендә ике юлда «ЗА ЗАСЛУГИ ПЕРЕД РЕСПУБЛИКОЙ ТАТАРСТАН» дигән язулар.

Барлык сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән.


Медаль көмеш лалә рәвешендәге декоратив элмәк һәм боҗра ярдәмендә яшел, ак, кызыл төстәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган бишпочмаклы колодкага беркетелә. Тасманың киңлеге – 24 мм, яшел һәм кызыл юлларның киңлеге – 11 мм, ак юлның киңлеге – 2 мм.

Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

Медаль белән бергә 10 га 24 мм зурлыктагы турыпочмаклы колодка рәвешендәге, яшел, ак һәм кызыл төстәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган планка бирелә. Тасманың уртасында көмеш лалә сурәте урнаштырылган. Яшел һәм кызыл юллар киңлеге – 11 мм, ак юл киңлеге – 2 мм.

«Татарстан Республикасы
алдындагы казанышлар өчен»
ордены медале тасвирламасына
кушымта

**«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медаленең төсле график сурәте**



Алгы ягы




Икенче ягы

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 16 » маендагы
ПУ- 336 номерлы Указына
4 нче кушымта

**«Фидакарь хезмәт өчен» медале тасвирламасы**

«Фидакарь хезмәт өчен» медале 925 нче пробалы көмештән ясала. Диаметры 32 миллиметрлы түгәрәк рәвешендә.


Медальнең алгы ягында уртада каймаланган түгәрәк сурәтләнгән. Түгәрәкнең уртасында – нефть вышкасы, ике төзелеш краны, архитектур капитель, КамАЗ автомобиле, ачык китап сурәтләре. Медальнең алгы ягында аскы өлешендә башаклардан үрелгән такыя сурәте, өстә – әйләнә буенча «ХЕЗМӘТКӘ ДАН – СЛАВА ТРУДУ» сүзләре, язу өстендә – әйләнә буенча тешле тәгәрмәч сурәте. Медальнең икенче ягында – дәфнә агачы ботагы сурәте, аның астында – медальнең номеры. Барлык сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән.

Медаль элмәк һәм божра ярдәмендә соры, яшел, ак, кызыл, соры төсләрдәге ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган бишпочмаклы колодкага беркетелә. Тасманың киңлеге – 24 мм, соры төстәге һәр юлның киңлеге – 8 мм, кызыл һәм яшел юлларның киңлеге – 3 мм, ак юлның киңлеге – 2 мм.


Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

«Фидакарь хезмәт өчен»
медале тасвирламасына
кушымта

**«Фидакарь хезмәт өчен» медаленең**
**төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 16 » маендагы
ПУ- 336 номерлы Указына
5 нче кушымта

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале тасвирламасы**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале 925 нче пробалы көмештән эшләнә һәм ике ягында да калку сыры булган 32 мм диаметрлы түгәрәк рәвешендә була.

Медальнең алгы ягында Татарстан Республикасының муниципаль районнар һәм шәһәр округлары чикләре схематик рәвештә сурәтләнгән алтынсу төстәге картасы төшерелгән.

Медаль әйләнәсе буйлап ике дәфнә агачы ботагы уза, алар аскы өлештә кисешә.

Медальнең өске өлешендә – Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте.

Медальнең икенче ягында уртада – медальнең номеры, өске өлешендә әйләнә ясап татар телендә өч юлга «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ҮСТЕРҮДӘГЕ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН» дигән язу, аскы өлешендә рус телендә өч юлга «ЗА ЗАСЛУГИ В РАЗВИТИИ МЕСТНОГО САМОУПРАВЛЕНИЯ В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН» дигән язу урнаштырылган.

Барлык сурәтләр кабарынкы итеп төшерелгән.


Медаль элмәк һәм бөҗра ярдәмендә ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган бишпочмаклы колодкага беркетелә. Тасманың киңлеге – 24 мм. Тасма дүрт төстә: тасманың ике кырыенда да – 2 мм киңлегендәге алтынсу төстәге юл, уртада – 2 мм киңлегендәге ак төстәге юл, аннан сулда – яшел төстәге юл, уңда – кызыл төстәге юл, аларның һәркайсы 9 мм киңлектә.

Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

___________

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарәне
үстерүдәге казанышлары өчен»
медале тасвирламасына
кушымта

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медаленең төсле график сурәте**



Алгы ягы




Икенче ягы

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «16» маендагы
ПУ-336 номерлы Указына
6 нчы кушымта

**«Ата-ана фидакарьлеге» медале**
**тасвирламасы**

«Ата-ана фидакарьлеге» медале алтын йөгертү ысулын кулланып, 925 нче пробалы көмештән ясала һәм таҗлары сулга, өскә һәм уң якка карый торган өч таҗлы көмеш лалә чәчәге рәвешендә була. Чәчәк алтын йөгертелгән тасма белән астан һәм кырыйлары буйлап каймаланган, тасманың очлары таҗлар артына кереп тора. Тасмага сулдан уңга таба рус телендә «РОДИТЕЛЬСКАЯ ДОБЛЕСТЬ», татар телендә «АТА-АНА ФИДАКАРЬЛЕГЕ» сүзләре язылган. Чәчәкнең өстендә чыбылдык корылган асылмалы бишек һәм бишек эчендә ятучы биләүгә биләнгән баланың алтын йөгертелгән сурәте ясалган. Медальнең киңлеге – 32 мм, уртадагы таҗның астан өскә кадәр биеклеге – 42 мм, алтын йөгертелгән тасманың киңлеге – 4 мм.

Медальнең икенче ягында – медальнең номеры; әйләнәсе буйлап татар халык бизәге төшерелгән, өске якта ул лалә чәчәге сурәте, ә аскы якта «ТАТАРСТАН» дигән язу белән өзелә.

Барлык сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән.

Ир-атлар костюмына яшел, ак, кызыл төстәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган бишпочмаклы колодка белән элмәк һәм божра ярдәмендә беркетелгән медаль тагыла. Тасманың киңлеге – 24 мм, яшел һәм кызыл юлларның киңлеге – 11 мм, ак юлның киңлеге – 2 мм. Колодканың үлчәме – 28 гә 35 мм.

Колодканың өске ягында – фигуралы алтын кыса.

Аскы ягында икесе ике якка караган алтын дәфнә агачы ботаклары, ботаклар элмәккә тоташтырылган. Колодканың өске һәм аскы ягында тишемнәр ясалган, алар аша ялтыравыклы ефәк тасма кидертелгән. Колодканың астында медальне киемгә беркетү өчен каптырма бар.

Хатын-кызлар костюмына яшел, ак, кызыл төстәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасмадан бант рәвешендәге колодка белән элмәк һәм божра ярдәмендә беркетелгән медаль тагыла.


Колодканың уртасында – вертикаль рәвештәге алтын дәфнә агачы ботагы куелган, аның элмәге бар. Ботак штифт ярдәмендә бантны 15 кә 25 мм зурлыктагы колодкага беркетә. Тасманың киңлеге – 24 мм, яшел һәм кызыл юлларның киңлеге – 11 мм, ак юлның киңлеге – 2 мм. Колодканың аскы ягында медальне киемгә беркетү өчен каптырма бар.

Медальнең төсле график сурәтләре кушымтада бирелә.

---

«Ата-ана фидакарьлеге» медале
тасвирламасына
кушымта

**Ир-атлар костюмына тагыла торган**
**«Ата-ана фидакарьлеге» медаленең**
**төсле график сурәте**





Алгы ягы




Икенче ягы

**Хатын-кызлар костюмына тагыла торган «Ата-ана фидакарьлеге» медаленең төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 16 » маендагы
ПУ- 336 номерлы Указына
7 нче кушымта

**«Ана даны – Материнская слава» медале**
**тасвирламасы**

«Ана даны – Материнская слава» медале көмешсыман төстәге металлдан ясала, 50 гә 43 мм үлчәмендәге яфраксыман пальметта формасында була.

Медальнең алгы ягында уртада уемтыкка беркетелгән мәрҗән урнаштырылган. Аскы өлештә лалә рәвешендәге кабарынкы чәчәк урнашкан, аннан уң һәм сул якка таба мәрҗән тирәли кабарынкы чәчәк-үсемлек орнаменты үрләгән.

Әйләнә ясап, сул якта татар телендә «АНА ДАНЫ», уң якта рус телендә «МАТЕРИНСКАЯ СЛАВА» дигән язулар урнаштырылган.

Медальнең икенче ягында уртада Татарстан Республикасының кабарынкы гербы урнаштырылган, аннан өстәрәк «МЕДАЛЬ» дигән язу бар. Гербтан 3 мм түбәнрәк – яфраксыман үсемлек орнаменты һәм медальнең тәртип номеры.


Медаль стилизацияләнгән, яшел, ак һәм кызыл төсләр кулланып бүлемтекләү техникасында башкарылган Татарстан Республикасының Дәүләт флагы рәвешендәге металл пластинка белән элмәк һәм боҗра ярдәмендә тоташтырылган.

Пластинканың икенче ягында медальне киемгә беркетү өчен каптырма бар.


Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

«Ана даны – Материнская слава»
медале тасвирламасына
кушымта

**«Ана даны – Материнская слава» медаленең төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «16» маендагы
ПУ-336 номерлы Указына
8 нче кушымта

**«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тасвирламасы**

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале 925 пробалы көмештән эшләнә һәм ике яктан да чыгынты рәвешендәге кыса белән каймаланган 32 мм диаметрлы түгәрәк рәвешендә була. Медальнең өслеге ялтыравыксыз, шомартылган.

Медальнең алгы ягында Татарстан Республикасы картасы силуэты сурәтләнгән, аның тирәли нурлар сузылган. Силуэт уртасында «ТАТАРСТАН» дигән язу төшерелгән.

Медальнең әйләнәсе буйлап татар халык бизәге төшерелгән, өске якта ул лалә чәчәге сурәте, ә аскы якта «1920–2020» язуы белән өзелә.

Нур бөркелгән карта силуэты бизәктән 25 мм диаметрлы түгәрәк буенча уза торган кыса белән аерылган.

Медальнең арткы ягында: уртада – медальнең номеры төшерелгән; әйләнәсе буйлап татар халык бизәге сурәтләнгән; кечерәк диаметрлы әйләнә буйлап өске өлештә татар телендә «ТАССР ТӨЗЕЛҮГӘ 100 ЕЛ», ә аскы өлештә рус телендә «100 ЛЕТ ОБРАЗОВАНИЯ ТАССР» дигән язу төшерелгән.


«ТАТАРСТАН» дигән язу медальнең төп көмеш фоны белән бертигез җирлектә башкарылган. Барлык башка сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән. Барлык кабарынкы элементларга 999 пробалы алтын йөгертелгән.

Медаль элмәк һәм божра ярдәмендә ефәк муар тасма белән тарттырылган бишпочмаклы металл колодкага беркетелгән. Тасманың киңлеге – 24 мм. Тасма берничә төстәге буй юлдан тора: сулдан уңга – зәңгәр төстә 1,5 миллиметрлы, кызыл төстә 10,5 миллиметрлы, яшел төстә 5,6 миллиметрлы, ак төстә 0,8 миллиметрлы, кызыл төстә 5,6 миллиметрлы.

Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.

«Татарстан Автономияле
Совет Социалистик Республикасы
төзелүгә 100 ел» медале
тасвирламасына
кушымта

**«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
төзелүгә 100 ел» медаленең
төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «16» маендагы
ПУ-336 номерлы Указына
9 нчы кушымта

**«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан»**
**медаленең тасвирламасы**

«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале 925 нче пробалы көмештән әзерләнә һәм ике яктан алтынсыман төстәге кыса белән каймаланган 32 мм диаметрлы түгәрәк рәвешендә була. Медальнең өслеге ялтыравыксыз, шомартып эшләнгән.

Медальнең алгы ягында әйләнәсе буйлап татар халык бизәге төшерелгән. Уртада Татарстанның географик картасы сурәтләнгән. Картада республиканың көньяк-көнчыгышы, гомуми шомартылган өлештән аермалы буларак, кабарынкы өслеге белән аерылып тора һәм, тулаем бөтен карта кебек үк, нечкә кайма белән уратып алынган.

Аерылып торган кабарынкы өлешенең үзәгендә өч миллиард тонна нефть чыгаруны гәүдәләндерүче фонтан рәвешендәге мемориал сурәтләнгән.

Республика картасы өстендә «3» саны, аскы өлешендә «ТАТАРСТАН» дигән язу урнаштырылган.

Татар халык бизәгенең эчке әйләнәсе буйлап бер юлга: сул якта – татар телендә «МИЛЛИАРД ТОННА НЕФТЬ», уң якта – рус телендә «МИЛЛИАРДА ТОННА НЕФТИ» дигән язулар урнаштырылган.

Медальнең икенче ягында уртада уентыклы өслек буенча – дәфнә агачы ботагы сурәте, аның астында – медальнең номеры.

Медаль әйләнәсе тирәли номер һәм ботак сурәтеннән чыгынтылы кайма белән бүленгән язулар урнаштырылган: шомартылган түгәрәкнең өстәге өлешендә – ике ягында дүрт кырлы ике йолдызы булган «1943 – 2007»; аннан соң әйләнә тирәли сулдан уңга таба чак кына кечерәк шрифтлы «1943–1971 – I млрд.», «1971–1981 – II млрд.» һәм «1981–2007 – III млрд.».

Барлык башка сурәтләр һәм язулар алтынсу төстә кабарынкы итеп төшерелгән.


Медаль элмәк һәм боҗра ярдәмендә ялтыравыклы ефәк тасма белән тарттырылган бишпочмаклы колодкага беркетелгән. Тасманың киңлеге – 24 мм. Тасма өч төстә: сулда – яшел төстәге юл, уңда – кызыл төстәге буй, һәркайсы 10 мм киңлегендә, тасма кырыйлары буйлап – 2 мм киңлектәге алтынсыман төстәге юллар.

Медальнең төсле график сурәте кушымтада бирелә.


___________

«Өч миллиард тонна Татарстан
нефтен чыгару уңаеннан»
медаленең тасвирламасына
кушымта

**«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан»**
**медаленең**
**төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «16» маендагы
ПУ-336 номерлы Указына
10 нчы кушымта

**Татарстан Республикасының мактаулы исемнәренә күкрәк тамгасының тасвирламасы**

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәренә күкрәк тамгасы 925 нче пробалы көмештән эшләнгән. Диаметры 32 мм булган түгәрәк рәвешендә.

Күкрәк тамгасының алгы ягында – алгы планда төрле зурлыктагы авыш полосалардан һәм биш почмаклы йолдыздан гыйбарәт динамик композиция сурәте, ул яңа хезмәт казанышларына ирешү омтылышын символлаштыра. Тамганың алтын йөгертелгән әйләнәсе буенча өзек кайма арасында түбәндәге сүзләр язылган:

сулда – «ХАЛЫК АРТИСТЫ», «ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ», «ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ», «ХАЛЫК УКЫТУЧЫСЫ», «ХАЛЫК РӘССАМЫ» һәм уңда тиешенчә – «НАРОДНЫЙ АРТИСТ», «НАРОДНЫЙ ПИСАТЕЛЬ», «НАРОДНЫЙ ПОЭТ», «НАРОДНЫЙ УЧИТЕЛЬ», «НАРОДНЫЙ ХУДОЖНИК» («Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясының 1–5 пунктлары нигезендә каралган мактаулы исемнәргә тамгалар өчен);

сулда – «АТКАЗАНГАН ХЕЗМӘТКӘР» һәм уңда – «ЗАСЛУЖЕННЫЙ РАБОТНИК» («Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясының 6–47 пунктлары нигезендә каралган мактаулы исемнәргә тамгалар өчен).

Тамганың икенче ягында «ТАТАРСТАН» дигән сүз, аның астында – дәфнә агачы ботагы сурәте.

Барлык сурәтләр һәм язулар кабарынкы итеп төшерелгән.

Күкрәк тамгасы элмәк һәм бошра ярдәмендә яшел-ак-кызыл төстәге (Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре) ялтыравыклы ефәк тасма белән тышланган бишпочмаклы колодкага беркетелгән. Тасманың киңлеге – 13 мм, яшел һәм кызыл юлларның киңлеге – 6 мм, ак юлның киңлеге – 1 мм.

Күкрәк тамгасының төсле график сурәтләре кушымтада бирелә.

---

Татарстан Республикасының
мактаулы исемнәренә
күкрәк тамгасының
тасвирламасына
кушымта

**«Татарстан Республикасының Халык артисты»**
**дигән мактаулы исемгә күкрәк тамгасының**
**төсле график сурәте**



Алгы ягы




Икенче ягы

**«Татарстан Республикасының Халык язучысы»**
**дигән мактаулы исемгә күкрәк тамгасының**
**төсле график сурәте**



Алгы ягы




Икенче ягы

**«Татарстан Республикасының Халык шагыйре»**
**дигән мактаулы исемгә күкрәк тамгасының**
**төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

**«Татарстан Республикасының Халык укытучысы» дигән мактаулы исемгә күкрәк тамгасының төсле график сурәте**



Алгы ягы




Икенче ягы

**«Татарстан Республикасының Халык рәссамы»
дигән мактаулы исемгә күкрәк тамгасының
төсле график сурәте**




Алгы ягы




Икенче ягы

**«Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясының 6–47 пунктлары нигезендә каралган мактаулы исемнәргә күкрәк тамгасының төсле график сурәте**



Алгы ягы




Икенче ягы

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 16 » маендагы
ПУ- 336 номерлы Указына
11 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының үз көчләрен югалткан дип танылган актлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2004 елның 16 июнендәге ПУ-460 номерлы Указы.

2. «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 25 ноябрендәге ПУ-728 номерлы Указы.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медаленең тасвирламасын һәм аңа таныклык формасын (үрнәген) раслау турында» 2007 елның 4 маендагы ПУ-221 номерлы Указы.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә таныклыклар формасын (үрнәкләрен) раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-396 номерлы Указының 2 пункты.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын, аңа таныклык формасын (үрнәген) һәм бүләкләү кәгазе формасын раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-397 номерлы Указы.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен» медале тасвирламасын раслау турында» 2011 елның 22 августындагы ПУ-510 номерлы Указы.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-876 номерлы Указы.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Дуслык» ордены һәм «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале тасвирламаларын раслау турында» 2015 елның 28 августындагы ПУ-809 номерлы Указы.

9. «Татарстан Республикасы Президентының «Дуслык» ордены һәм «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале тасвирламаларын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 2 сентябрендәге ПУ-824 номерлы Указы.

10. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы Указына кушымтаның 2 пункты.

11. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тасвирламасын раслау турында» 2019 елның 12 октябрендәге ПУ-620 номерлы Указы.

12. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы орденнарын, медальләрен һәм күкрәк тамгаларын әзерләүне оештыру турында» 2004 елның 16 июнендәге 113 номерлы боерыгы.

---